| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от** 10.09.2013 Казан ш **№** 255

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 24.04.2010 ел, №362 боерыгына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.06.2012 ел, № 168 боерыгы редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар белән тәңгәлләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м :

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 24.04.2010 ел, №362 боерыгына (алга таба – Боерык) (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.06.2012 ел, № 168 боерыгы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкка 1 нче кушымтада:

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче һәм өченче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22.1 статьясы нигезендә әлеге пунктның беренче абзацында аталган затлар белән бергә иҗтимагый совет төзелде, Дәүләт комитетындагы конкурс комиссиясе составына әлеге иҗтимагый совет вәкилләре дә кертелә. Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары әлеге совет тарафыннан Дәүләт комитеты рәисенең гаризасы буенча тәкъдим ителә.»;

2.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле җымлә өстәргә:

«Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына уздыру рөхсәт ителми.»;

4.4.8 пунктында:

4.4.8.1 пунктчасында «граждан хезмәтенең өлкән вазыйфаларына» сүзләрен «граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән төркемнәренә» сүзләренә алмаштырырга;

4.4.8.2 пунктчасында «әйдәп баручы граждан хезмәте вазыйфаларына» сүзләрен «граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалары төркеменә» сүзләренә алмаштырырга;

4.4.8.3 пунктчасында «граждан хезмәтенең төп вазыйфаларына» сүзләрен «граждан хезмәте вазыйфаларының төп төркемнәренә» сүзләренә алмаштырырга;

Боерыкка 4 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен белемгә һәм дәүләт хезмәте стажына һәм эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре:

2.1.1. дәүләт хезмәте вазыйфаларының барлык категорияләре – югары һөнәри белем, дәүләт хезмәтенең әйдәп баручы яки өлкән төркеме вазыйфаларында кимендә ике ел дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек буенча кимендә өч ел хезмәт стажы;

2.1.2. дәүләт хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең барлык категорияләре – югары һөнәри белем, дәүләт хезмәтенең өлкән яки кече төркеме вазыйфаларында бер елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы;

2.1.3. дәүләт хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәрендә «тәэмин итүче белгечләр» категориясе – эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган урта һөнәри белем булу.»;

2 нче кушымтаны әлеге Боерыкка кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Мәгълүматлаштыру бүлегенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган тиешле мәгълүмат бүлегенә үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11 сентябрь, 2013 ел, № 255 боерыгына кушымта

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2010 елның 24 декабрендәге 362 номерлы боерыгына 2 нче кушымта

«Җитәкчеләр» категориясе буенча дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе:<br>Зарипов Марат Ривгать улы | - Дәүләт комитеты рәисе; |
| Комиссия рәисе урынбасары:<br>Толстая Тамара Александровна | - кадрлар бүлеге башлыгы; |
| Комиссия секретаре:<br>Әминова Галия Шәмсетдин кызы | - кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Садыйкова Эльмира Җәмил кызы | - юридик бүлек башлыгы; |
| Хәбибуллина Лариса Васильевна | - коммуналь өлкә оешмаларын җайга салу идарәсе башлыгы; |
| | - су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу һәм каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү өлкәсендә тарифларны җайга салу бүлеге башлыгы; |
| | - Дәүләт комитеты рәисе урынбасары, бүлекчәне җитәкли; |
| | - Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты вәкиле (килешү буенча); |
| | - белем бирү учреждениеләре вәкиле |
| | - бәйсез эксперт (килешү буенча); |

«Белгечләр», «тәэмин итүче белгечләр» категорияләре буенча дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе:<br>Штром Александр Леонидович | - Дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары; |
| Комиссия рәисе урынбасары:<br>Толстая Тамара Александровна | - кадрлар бүлеге башлыгы; |
| Комиссия секретаре:<br>Әминова Галия Шәмсетдин кызы | - кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Садыйкова Эльмира Җәмил кызы | - юридик бүлек башлыгы; |
| Хәбибуллина Лариса Васильевна | - коммуналь өлкә оешмаларын җайга салу идарәсе башлыгы, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу һәм каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү өлкәсендә тарифларны җайга салу бүлеге башлыгы; |
| | - граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган бүлекчә җитәкчесе; |
| | - Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты вәкиле (килешү буенча); |
| | - белем бирү учреждениеләре вәкиле – бәйсез эксперт (килешү буенча); |
| | - Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле (килешү буенча).». |